**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Тоншерма торак пунктында халык җыены карары**

**30 .11. 2021** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Тоншерма Келәш авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Тоншерма Келәш авыл җирлеге торак пункты территориясендә 2022 елда һәр балигъ булмаган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә.

2. Гражданнардан алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); Чапаев урамы буенча 16-нчы номерлы йорттан Ленин урамы буенча 54-нче номерлы йортка кадәр.;

- Тоншерма торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (су башнясы янында павильон төзү: төзелеш материаллары сатып алу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

-Тоншерма т.п. урнашкан буаны чистарту эшләрен башкару өчен проект-смета документациясен эшләү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Келәш авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Х. Галимов**